КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 октябрь г.Казань № 984

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы социаль хезмәтләре дәүләт системасы хезмәткәрләренең гомуми файдаланудагы транспортта йөрүе турында» 2005 ел, 15 июнь, 271 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы социаль хезмәтләре дәүләт системасы хезмәткәрләренең гомуми файдаланудагы транспортта йөрүе турында» 2005 ел, 15 июнь, 271 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «социаль хезмәтләре дәүләт системасы» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында һәм «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләре хезмәт максатларында гомуми файдаланудагы транспортның барлык төрләренә, шул исәптән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы үзәкләштерелгән сатып ала торган шәһәр яны (таксидан тыш) юл документлары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә тәэмин ителә дип билгеләргә.»;

2 пунктта «социаль хезмәтләре дәүләт системасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарны гамәлгә ашыру чыгымнары Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җиткерелгән тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

4 пунктта «Министрлык» сүзеннән соң «хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Социаль хезмәтләр күрсәтү буенча хезмәт эшчәнлеге юл йөрүләр белән бәйле булу шарты белән, юл йөрү документларын алу хокукы булган социаль хезмәтләр дәүләт системасы хезмәткәрләре вазыйфалары исемлегендә:

исемендә «социаль хезмәтләре дәүләт системасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктлар өстәргә:

«6. Карау буенча ярдәмче.

7. Гаилә белән эшләү буенча белгеч.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин